Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

# ТЫЛСЫМ+

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

№4 (58)

Гыйнвар, 2024 нче ел

Бу санда

*Гимназия сулышы* 2

*Күңел җылысын кушып...* 2

*Үгет-нәсыйхәт – бездән, әдәп белү – үзеңнән* 3

*Үземә-үзем психолог* 3

*Укучылар иҗаты* 4

*Мин гаилəм белән бәхетле* 4



Гаилә –
кешене кешелекле булырга
өйрәтә торган өй мәктәбе ул.

«ТЫЛСЫМ+» газетасы

«МИН ГАИЛӘМ БЕЛӘН БӘХЕТЛЕ»

рубрикасына гаилә белән төшкән фотолар (спорт, китап уку, хезмәт белән бәйле) һәм язмалар кабул итә.

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Россиядә — Гаилә елы, Татарстанда — Фәнни-технологик үсеш елы

Яңа 2024 нче елга да аяк бастык. Алда яңа бурычлар, яңа максатлар көтә. Гимназиябездә яңа елның беренче көннәреннән үк эш гөрли. Каникулда ял итеп, көч җыеп килгән укучыларыбыз өченче чирекне башлап җибәрделәр. Имтиханнарга әзерлек бара.

Педагогик киңәшмәдә артта калган уку чорына нәтиҗә ясалды. Белем һәм тәрбия бирүдәге күрсәткечләр һәрвакыт алгарышта. Мәктәп коллективына, укучыларга ихластан рәхмәт. Агымдагы елда барлык матур башлангычларны дәвам итеп, тагын да югарырак биеклеккә ирешергә язсын. Ә безне нинди ел көтә соң?

Соңгы елларда һәр яңа килгән елны аерым бер тармакка багышлап уздыру гадәткә керде. Әйтик, үткән 2023 - Россиядә Укытучылар һәм остазлар, Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы буларак узды. 2024 ел Россия Президенты Владимир Путин Указы нигезендә - Гаилә, Татарстан Республикасы Рәисе Указы нигезендә Фәнни-технологик үсеш елы булачак.

### Фән олимпиадасы көндәлегеннән:



***Республикада фән олимпиадаларының Республика турлары башланып китте. Укучылар өчен уздырыла торган фән олимпиадаларының рәсәй һәм республикакүләм турында Мөслим гимназиясе укучылары да катнаша.***

Нәтиҗәләр дә куандыра: 10 нчы а сыйныфы укучылары **Гәрдеева Әмирә** инглиз теле буенча, **Шәрифуллин Рәфил** математикадан, 9 нчы в сыйныф укучысы **Дәүләтшин Әмир**, шулай ук математикадан "Олимпка юл" республика укучылар олимпиадасы призлы урыннарга лаек булдылар.

Укытучылары - Мөхәммәтҗанова Гөлшат Ильяс кызы, Асылгәрәева Гөлүсә Әсгат кызы һәм Госсамова Рәмилә Сабирҗан кызы.

9 нчы в сыйныф укучысы **Габидуллина Азалия**, 11 нче сыйныф укучылары **Ахунова Рәзилә** һәм **Зиннуров Илдар** рус теленнән Россиякүләм предмет олимпиадасының регион этабында призер булдылар. Укучыларны олимпиадага Хәйруллина Чулпан Алмаз кызы әзерләде. 7 нче а сыйныфы укучысы **Хафизова Әминә** физик тәрбия фәненнән призер. Укытучысы – Шәйхетдинов Дамир Гәйнетдин улы.

Укучыларны һәм укытучыларны зур уңышлары белән ихластан котлыйбыз!!! Уңышлар дәвамлы







# ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

## Педагогик киңәшмә үтте



Гимназиябездә II чирек йомгаклары буенча педагогик киңәшмә үтте. Киңәшмәне гимназия директоры Мирзаянов Азат Фәрит улы үткәрде.


Киңәшмәдә директор урынбасары Заялова Лира Нурфаяз кызы II чиректә укучыларның өлгерешенә тулы анализ ясады. Фән олимпиадаларының муниципаль турындагы нәтиҗәләр белән директор урынбасары Мөхәммәтҗанова Гөлшат Ильяс кызы таныштырды. Башлангыч сыйныф укытучылары: Исмәгыйлова Г.Ф., Мортазина Л.Г., Мирзасалихова Г.Ш. үз эш алымнары белән таныштырдылар.

Киңәшмәгә нәтиҗә ясап, Азат Фаритович белем бирү барышында сферум, онлайн платформаларда укучылар белән актив һәм индивидуаль эшләргә, яңа алымнарны кулланырга, грантларда актив катнашырга чакырды.

## Гимназия укучылары сынатмый




26 нчы гыйнварда Түбән Кама шәһәрендә “Без - XXI гасыр киләчәге” исемле VIII региональ фәнни-гамәли конференциядә узды. Гимназиябезнең 3 нче в сыйныфы укучысы Нассер Фирас лауреат исеменә лаек булды (җитәкчесе Хасанова М.К.).



Әлмәт шәһәренең Кванториум базасында IV Бөтенрәсәй “РобототДатели” конкурсы үтте. Конкурста төрле төбәкләрдән 65 укучы катнашты. Гимназиябезнең 1 нче а сыйныфы укучысы Тимергалиев Зөлфәт “Робо-Растения” номинациясендә III урын яулады.

## Яңа электрон көндәлек




Яңа ел каникулларыннан соң мәктәпләрдә edu.tatar.ru порталы эшләүдән туктады, аңа алмашка ms-edu.tatar.ru сайты кертелде. “Я – школьник” һәм “Моя школа. Дневник” кушымталары аша кереп була.

## Әйләнә-тирәбездә IT




ШАНС республика мәгариф челтәрләре мәйданчыгында "Әйләнә-тирәбездә IT” проектына йомгак ясалды. Әлеге проект икенче чиректә shans177.ru сайтында үткәрелде. Проектта республикабыз мәктәпләреннән 5-6, 7-8, 8-9 сыйныф укучыларыннан торган командалар катнашты. Барлыгы: 43 команда, 120гә якын укучы.

Гимназия укучыларыннан торган ике команда - “Инфознайка” (5-6 нчы сыйныфлар) һәм “МатрицаМ” (8-9 нчы сыйныфлар) квест биремнәрен үтәделәр.

Нәтиҗәдә, “Инфознайка” командасы лауреат, “МатрицаМ” командасы икенче урынга лаек булды. Командаларның җитәкчесе информатика укытучысы Кадирова А.Р. Уңышларыгыз белән котлыйбыз!

## Күңел җылысын кушып...



Соңгы арада окоп шәмнәре ясау активлаша башлады. Әлеге шәмнәрне махсус хәрби операциядә булучы хәрбиләр куллана. Ул окоп шәмнәре 8 сәгатькә кадәр җылылык бирер тора ала икән.

Салауз Мухан авылы активисты һәм волонтеры Әюпова Илмира Әхнәф кызы 8 нче а сыйныф укучылары өчен озак янулы окоп шәмнәре ясау буенча мастер-класс үткәрде.

Мондый шәмнәр көчле җил булганда да сүнми һәм 10 минутка кадәр яна ала. Балалар ясаган шәмнәр махсус хәрби операция зонасында катнашучыларга тапшырылачак.



## ҮГЕТ-НӘСЫЙХӘТ – БЕЗДӘН, ӘДӘП БЕЛҮ – ҮЗЕҢНӘН

***Гыйнвар хокук бозуларны кисәтү айлыгы, шул уңайдан гимназиядә дә төрле чаралар үткәрелә.***

### Хокук бозуларны кисәтү



Яшүсмер чак – кеше тормышындагы иң актив чордыр, мөгаен. Физик көченең артуын сизгән һәм җитлегә баручы үсмергә ул инде барысын да булдыра ала кебек тоела. Ләкин тормыш тәҗрибәсе җитмәү, җинаять җаваплылыгын, законнарны белмәү, еш кына үз-үзеңне кулда тота алмау да аяныч нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Ә хокук тәртибен бозганда закон нигезендә җавап бирергә туры киләчәк.

Яшүсмерләр арасында киң таралган җинаять төрләренә урлашу, талап алу, хулиганлык һәм наркоманлык керә. Шушындый күңелсез хәлләр килеп чыкмасын өчен үз-үзен тотуда тайпылышлары булган балаларга гаилә, мәктәп һәм хокук саклау органнарының ярдәм булуы бик мөһим.

Гимназиядә бу юнәлештә актив рәвештә эш алып барыла. Аның максаты: укучыларда югары әхлаклылык, җәмәгать урыннарында үз-үзеңне дөрес тоту һәм эш-хәрәкәтләренә, тәртибенә контрольлек итә белү сыйфатлары тәрбияләү. Бурычлары: негатив күренешләргә “юк” дип әйтә белүче, үзенең сүзе белән башкаларга да ярдәм итә алучы шәхес тәрбияләү. Хокук бозуларны кисәтү буенча эшчәнлек мәктәп үзидарәсе, сыйныф җитәкчеләре, әти-әниләр комитетлары, район социаль үзәк хезмәткәрләре, бәлигъ булмаган балалар белән эшләүче инспектор белән тыгыз элемтәдә алып барыла.

Аларның эшчәнлеге нидән гыйбарәт соң? “Гасыр афәте наркомания”, “Эчкечелекнең зарары”, “Тәмәке тарту – начар гадәт”, “Куркынычсызлык техникасы кагыйдәләре белән таныш бул!” дигән темаларга әңгәмәләр, хокук бозуларны кисәтү һәм булдырмау буенча “Бала хокуклары иленә сәяхәт”, “Мин - бала, мин - кеше”, “Электрон тәмәкегә урын юк”, “Наркомания турында мифлар, “Дустың үзеңнән яхшырак булсын”, “Саулыгыңны яшьтән сакла!” темаларына сыйныф сәгатьләре үткәрелә.

Гимназиядә күпбалалы, социаль



яктан мохтаҗ булган гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар һәрчак игътибар үзәгендә тора. Аларны төрле спорт секцияләренә, түгәрәкләргә тарту уңышлы нәтиҗә бирә. Нәтиҗәдә «риск группасына» керүчеләрнең саны кими.

Югарыда әйтелгәннәрне искә алып, мәктәп коллективы, укучылар төркеме алдында әхлакый һәм хокук бозуга каршы профилактик эшне тагын да үстерү, бу эштә яңа технологияләр куллану, бердәм эшләү максаты куела. Безнең эш күрсәткече булып уңай нәтиҗә торырга тиеш.

Укучыларның дәрестән тыш вакытларын, каникулларын хәвеф-хәтәрсез уздыру ата-аналар һәм укучыларның бердәм бурычы. Бүгенге алга киткән җәмгыять шартларында гаилә, мәктәп, хокук саклау органнары бердәм булса гына балаларыбызны ялгышулардан саклап, дөрес юлдан китәргә ярдәм итә алачакбыз.

***Әмирова Миләүшә,***
***гимназиянең социаль педагогы***

## ҮЗЕМӘ-ҮЗЕМ ПСИХОЛОГ

### Уку ялыктырдымы?

Хәзерге мәктәп укучылар тормышында стресслар җитәрлек: имтиханнарга әзерлек, өй эше, өстәмә дәресләр... Бу проблема урта һәм югары сыйныфларда еш очрый. Ял итмичә, көндәлек режимны кабатлап тору организмның эмоциональ аруына китерә. Моны игътибарсыз калдырырга ярамый. Мәктәптәге ару-талуны ничек бетерергә соң?

Сезгә берничә киңәш тәкъдим итәбез.

**Тәнәфес ясап ал**

Мөмкин булса, тәнәфес ясa. Атна саен ким дигәндә бер көнеңне укуга түгел, ялга багышла: яраткан китабыңны укы, күптән карарга теләгән фильм яки спектакль кара, гардеробыңны яңарт.

**Вакытыңны кызганма**


Башка көннәрдә дә күңелле чаралар өчен вакытыңны калдыр! Атна дәвамында календареңны яраткан шөгыльләрең белән тутыр. Өй эшләрен эшләгән арада булса да аларны башкарырга тырыш. Һәм син күбрәк мотивация алырсың.

**Физик күнегүләр эшлә**

Ким дигәндә атнага өч тапкыр күнегүләр ясa. Файдалы ризыкларны күбрәк ашарга тырыш. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, табигатьтә уздырган вакыт стресс дәрәҗәсен киметә. Шуңа күрә буш вакытыңда өйдә утырма.

**Мотивация булдыр**

Алга таба планнарың нинди? Син кем булырга, нинди һөнәр алырга телисең? Нәрсә өчен белем алганыңны һәм нинди мак-



сатың булганын исеңә төшер. Уку – үзмаксат түгел, аның артында мөһимрәк әйберләр бар. Һәрвакыт алга барырга дигән максат куй. Һәм шул вакытта алга барырга көчең җитәр.

**Шушы гади адымнар белән син ару-талуны җиңә алачаксың. Үзең белән үзең идарә итәргә өйрән. Барысы да синнән тора!**

## МИН ГАИЛӘМ БЕЛӘН БӘХЕТЛЕ






**Шәйгардановлар гаиләсе -**
*"Сәнгатькә гашыйк гаилә"*

## УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ

### Зирәккә дә тәрбия кирәк

*(хикәя)*



Миңа ике яшьләр булганда, Энҗе апам песи баласы алып кайтты. Хәер, аның безнең йортта ничек пәйда булганын мин хәтерләмим. Чөнки бик кечкенә булганмын. Мин үсә төштем, минем белән песи баласы да үсте. Аның исеме - Зирәк. Ул бик матур: аклы-җирән төстә, ә күзләре ямь-яшел. Зирәк бар нәрсәне аңлаган кебек, шундый акыллы итеп карый. Ләкин аның бик начар гадәте бар: аш өстәлендә нәрсә бар, шуны менеп урлый. Песинең бу гадәтен әти ошатмады. Беркөнне, түземлеге бетеп:

- Зирәк бүгеннән башлап, тышта яшиячәк! Абзарда җылы, кирәк булса, сәндерәгә менеп йоклар, – диде.

Безнең гаиләдә әтинең сүзе – закон. Беркем дә каршы сүз әйтмәде. Зирәк абзарда яши башлады. Аны һәр көнне җылы аш, сөт белән сыйлыйбыз. Ә пескәй әтинең күңелен йомшартырга теләгәндәй, әле тычкан, әле кумак әләктерә. Тоткан тычканын әтинең аяк астына алып килеп ташлый, үзенчә мактанган була. Әти аны: "Булдыргансың! Акыллы шул бик син!" - дип мактап куя.

Энҗе апам институтка укырга керде. Ул ялларга кайтып, кире укырга киткән чакта, Зирәк һәрвакыт апамны озатып кала торган булды. Мин Зирәкне бик яратам. Песием эчтән генә ниләр уйлый микән? Аның яшел, акыллы күзләрендә ниләр яшеренгән? Минә шул хакта минем бик тә беләсем килә! Шул максат белән песиләр хакында интернет челтәреннән бик күп мәгълүмат-лар укыйм. Белгәннәремне әни белән уртаклашам:

- Әни! Беләсеңме, песиләр хуҗаларын - әти-әниләре, туганна-ры итеп кабул итә икән! Ә этләр – дуслары итеп. Чөнки, борын-борын заманда песиләр үз гаиләләре белән генә, ә этләр көтүләр булып яшәгәннәр.

- Каян белдең бу хакта? - ди әни, гаҗәпләнеп.

- Интернеттан укыдым!

Әни бераз миңа курыккан кыяфәттә карап торды да:

- Ничек килеп чыга, без үзебезнең баланы тышка куып чыгардык мени?!

- Шулай килеп чыга, - дидем мин, авыр сулап.

- Юк! Болай ярамый! Мин Зирәкне өйгә алып керәм! - диде әни, катгый карарга килеп.

Әнием Зирәкне өйгә алып керде. Песинең ап-ак йоннары каралган, колаклары кителгән, ә борынына томау төшкән.

- И бичара, яше дә шактый бит инде, - дип сөйләнде әни. Зирәкне җылы мунчага алып барып, табакка утыртып юындырдык. Ни гаҗәп, песиебез тыпырчынмады, җылы суда изрәп, мырлый гына бирде. Аны чүпрәккә төреп, корыттык та, өйгә урын әзерләп яткырдык. Песиебез рәхәтләнеп йоклап китте.

Әни Зирәккә ике савыт әзерләде: берсе су, икенчесе ризык өчен.

Аның савытларын чистартып тору – сезнең өстә! - диде әни, энем белән миңа. – Тагын бер нәрсәне исегездән чыгармагыз: "урлаган – бер гаепле, урлаткан – ике" дигәннәр борынгылар. Аш өстәлен җыеп йөрсәк, песи дә урлашырга менмәс, менсә дә коры төшәр. Зирәкне тәрбияләү – безнең бурыч. Ул бит безнең гаилә әгъзасы! - дип өстәде, миңа елмаеп әнием.

Ләкин бер мәсьәлә әле чишелмәгән иде.

- Ә әти ни әйтер? - диде энем, күзләрен зур ачып.

- Борчылмагыз! Әтиегез белән мин үзем сөйләшермен.

Шулай итеп, Зирәк өйдә яши башлады. Песи күзгә күренеп тазарды, матурланды. Аның булуы әйтеп бетергесез, өйгә ямь өстәде. Һәрберебез Зирәкнең кыланмыш-ларына сокланып та, гаҗәпләнеп тә карыйбыз, аның белән сөйләшә башлады. Хәтта әти дә: "Нәрсә, Зирәк, бүген тәртипле булдыңмы?" - дип, аны сыйпап та ала башлады. Әлбәттә инде, без аңа Зирәкнең кайчагында арт аякларына басып, буш өстәл өстен күзәткәләгәнен әйтмибез!

***Зәкиева Әминә,***
***7 нче в сыйныфы укучысы***

ТЫЛСЫМ+
**Гыйнвар, 2024 нче ел**
**№4 (58)**
***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.

**Мөхәррир:** Мингазова Камилә
**Корректорлар:** Мингазова Диләрә
**Корреспондентлар:** Насырова Мәрьям
Замалова Зәринә
**Дизайнер:** Садриев Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Латыпов Илназ
Хаертдинов Ранис

***2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә***

**Гамәлгә куючы:**
Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3)
**Тираж:** 100